ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОИБРАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Кооперативная, дом 2,
село Старое Ибрайкино, 423078

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ИБРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооператив урамы, 2 енче йорт
Иске Ибрай авылы , 423078

# КАРАР

№ 9

27 октябрь 2025 ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге Башкарма комитеты "Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 20.09.2024 елгы 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 31.07.2025 елгы 304-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясындагы 3 пунктының г, д пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАРы:

1.Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге Башкарма комитеты 20.09.2024 № 8 карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктының 4 пунктчасында "мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк" сүзләрен "мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк"сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктында түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктчасы өстәргә::

"4.1)Мөрәҗәгать итүче булмаган затның персональ белешмәләре бирелгән очракта, федераль башкарма хакимият органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәү өчен ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасы аша мондый затның яисә аның шәхси белешмәләр эшкәртүгә законлы вәкиленең күрсәтелгән максатларда ризалыгын алу таләп ителми.""
2.Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы рәсми сайтына (http://aksubaevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3.Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Ибрай авылҗирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе

М. Г. Миңнегулов